БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«__04__» ____04_____ 2020 ел № _142_

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында социаль ярдәм чараларын бирү вакытын озайту турында**

Коронавирус инфекциясе таралу куркынычын минимальләштерү максатларында Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Түләү чоры 2020 елның 30 сентябренә кадәр бетә торган, «Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2013 елның 27 сентябрендәге 203 номерлы карары белән (2009 елның 25 декабрендәге 386 номерлы үзгәрешләр белән) билгеләнгән социаль ярдәм чараларын бирүне дәүләт һәм муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләве өлешенең өстәмә компенсациясен алучы гражданнарга, 20,0 мең сумга кадәр уртача керемле гаиләләргә бу ярдәмне алу өчен гаризаны кабат тапшырмыйча гына 2020 елның 1 октябренә кадәр озайтырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми baltasi.tatarstan.ru сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов